ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**№ 37** **«24» мая 2019 г.**

2019-2021 елларга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл
җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларын үстерү Программасын раслау турында

Ютазы районы прокуроры күрсәтмәсен карап, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209 - ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү Программасын (алга таба – Программаны) расларга.
2. 2019 елга программаны финанслау каралмаган дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.yutaza.tatar.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы Димтамак
авыл җирлеге башлыгы урынбасары Х.М.Хәлиуллина.

Ютазы муниципаль районы
Димтамак  авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
Кушымта №

# 2019-2020 елларга  Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү ПРОГРАММАСЫ

Димтамак авылы

**2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасының ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон; |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның төп максатлары | Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең социаль-икътисади бурычларын хәл итүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тудыру һәм аларның ролен күтәрү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итү;<br>- Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына алар җитештергән товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатуда (в продвижении) ярдәм күрсәтү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;<br>- халыкны эш белән тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү;<br>- талантлы яшьләрне һәм потенциаль идарәчеләрне ачыклау һәм кече һәм урта эшкуарлыкка җәлеп итү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан түләнгән барлык дәрәҗәдәге бюджетларның салым керемнәре өлешен арттыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2019-2021 еллар |
| Программаның төп чаралары исемлеге | - кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартларны камилләштерү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати, консультатив һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә социаль яклау һәм хезмәтне саклау механизмнарын гамәлгә кертү. . |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын 10 процентка арттыру;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләренең уртача санын 2020 елга карата, 2018 ел белән чагыштырганда, 10 % ка арттыру; |

| | |
|---|---|
| | - кече һәм урта эшмәкәрлектә уртача хезмәт хакы күләмен уртача тармак дәрәҗәсенә кадәр арттыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен 10 процентка кадәр арттыру;<br>- җирлекнең инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту;<br>- кече һәм урта бизнес оешмаларының үз көчләре белән җитештергән, башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү күләме, 2018 ел белән чагыштырганда, 2020 елга 10% ка арттыру; |
| Программаны финанслау күләме һәм финанслау чыганаклары | Татарстан Республикасы бюджеты, район бюджеты, бюджеттан тыш фонд чаралары, эшкуарларның үз акчалары һәм җәлеп ителгән инвестицияләр |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1.Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Программа 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында " 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү мәсьәләләре керә.

2008 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында " 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү өчен шартлар тудыру кертелгән .

Әлеге программаның максатлары һәм төп бурычлары Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Программа Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең чараларны тормышка ашыру өчен җаваплы кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә максатларга ирешүгә, эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген билгели.

## 2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү нигезләре

Кече һәм урта эшмәкәрлек Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең икътисади һәм социаль бурычларын хәл итүдә мөһим роль уйный, чөнки яңа эш урыннары булдыру, кулланучылар базарын товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән баетуга, конкурентлы мохит булдыруга ярдәм итә, җирлек халкының икътисадый мөстәкыйльлеген, салым кертемнәренең тотрыклылыгын тәэмин итә. Эшкуарлыкны үстерү Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешендәге өстенлекле бурычларның берсе булып тора.

Бүгенге көндә Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә 7  шәхси эшмәкәр теркәлгән.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенең төп төре: кибетләрдә азык-төлек һәм сәнәгать товарлары белән ваклап сату.

Җирлектәге авыл хуҗалыгы предприятиеләре эшчәнлегенең төп юнәлеше – бөртекле культуралар, ит, сөт җитештерү. Авыл хуҗалыгы тармагында төп проблема булып төп фондларның искергәнлеге, сатыла торган продукция өчен түбән бәяләр һәм җитештерү чыгымнарын капламый торган  түбән субсидияләр түләү ставкалары  кала.

Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешендә тоткарлаучы факторларны проблемаларның өч төркеменә бүләргә мөмкин:

1. оештыру проблемалары (предприятиене юридик рәсмиләштерү һәм теркәү белән кыенлыклар, шәхси эшне ачу һәм үстерү өчен кирәкле рөхсәт документларын (лицензия һ. б.)  алу, банкта счет ачу һ. б. проблемалар);
2. матди-техник тәэмин ителеш (җитештерү һәм хезмәт урыннары, заманча җиһазлар җитмәү яки булмау, персоналның квалификациясе түбән булу, эшмәкәрләр эшчәнлегенең тиешенчә яклanмаган булуы);
3. матди-финанс проблемалары:

- предприятиене теркәү өчен капитал алуда кыенлыклар;
- әйләнештәге акча җитмәү;
- шәхси, шулай ук эшчәнлеген киңәйтү өчен бурычка алынган финанс чаралары җитешмәве.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының күбесе финанс хәле тотрыклы булмавы һәм акча җитмәү аркасында үз үсеше, яңа технологияләр кертү, продукциянең һәм хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү, озак сроклы инвестицияләр кертү, яңа базарлар үзләштерү өчен эчке стимуллардан мәхрүм. Эшмәкәрләрнең төп өлеше кредит һәм бурыч чаралары файдаланмый, барыннан да элек, кирәкле тәэмин ителеш  булмау сәбәпле һәм һәм кредит вакыйгалары_ аркасында . Гадәттәгечә, коммерция банклары кече һәм урта бизнес субъектларын  хезмәт күрсәтүдә катлаулы, югары рисклы һәм чагыштырмача түбән керемле дип саныйлар. Югары кредит рискларын банклар эре бизнес мөнәсәбәтендә  югары процент ставкалары белән компенсацияләргә тырыша. Шуңа бәйле рәвештә, кече һәм урта бизнеска кредит бирү процессы массакүләм булмады әле.

Күпчелек эшмәкәрләр идарә һәм коммерция карарлары кабул итү өчен бизнес алып баруның төрле аспектлары турында мәгълүматка мохтаҗ.  Кече

һәм урта бизнесны мәгълүмати тәэмин итү проблемасы турыдан-туры консультация бирү һәм тематик (махсуслаштырылган) басмалар кебек традицион формаларны кулланып хәл ителергә мөмкин.

Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты кече һәм урта эшкуарлыкны социаль тотрыклылыкның ышанычлы гаранты буларак карый һәм эшмәкәрлек эшчәнлегенә эшкә сәләтле аз керемле һәм эшсез кешеләрне җәлеп итү бурычын хәл итә.

Җирлекнең реаль икътисади потенциалы әле бетмәгән, кече һәм урта бизнеста булган проблемалар аз түгел, аларны әле хәл итәргә кирәк. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыруга, кече һәм урта бизнес өлкәсендә халыкның эш белән тәэмин ителешен күбәйтүгә, Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге икътисадының барлык тармакларында кече һәм урта бизнес предприятиеләре тарафыннан җитештерелгән продукция күләмен арттыруга җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү механизмнарын активлаштыру, тырышлыкны берләштерү һәм үзара килешеп эшләү юлы белән генә ирешергә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын кабул итү зарурлыгы туа. Әлеге программаны кабул итү өчен хокукый нигез булып 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон тора.

Программа кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс, мәгълүмати, консультацион һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү, шулай ук контроль процессын оештыру өчен норматив-хокукый базаны булдыру буенча комплекслы эш планы булып тора.

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

3.1. Программаның төп максатлары булып тора:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең социаль-икътисади бурычларын хәл итүдә аларның ролен арттыру өчен уңай шартлар тудыру;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итү;
- Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына алар җитештергән товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга этәрүдә ярдәм күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;
- халыкны эш белән тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү;
- кече эшкуарлыкка талантлы яшьләрне һәм потенциаль идарәчеләрне ачыклау һәм җәлеп итү;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан түләнгән барлык дәрәҗәдәге бюджетлардагы салым керемнәре өлешен арттыру;

Куелган максатларга ирешү Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләре һәм эшмәкәрләрнең коммерцияле булмаган оешмалары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән ведомствоара хезмәттәшлек принципларында тормышка ашыру тәкъдим ителә.

3.2. Куелган максатларга ирешү өчен хәл итәргә кирәк булган бурычлар:

- кече һәм урта эшмәкәрлекнең көндәшлеккә сәләтлелеген һәм инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру;

- кече һәм урта эшкуарлыкка җирлек икътисадының өстенлекле тармакларында ярдәм итү: инновацион эшчәнлек; хезмәт күрсәтүләр (көнкүреш, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә); азык-төлек (сөт, ит), милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, һөнәрчелек; авыл хуҗалыгы (крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәме күрсәтү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультацион һәм оештыру ярдәме күрсәтү;

Программаның бурычлары аның соңгы максаты белән билгеләнә һәм эшкуарлык эшчәнлеген активлаштыруга, яңа эш урыннары булдыруга һәм эшкуарлыкка җәлеп ителгән халыкның киң катламының иминлеген арттыруга ярдәм итә торган уңай мохит тудырудан гыйбарәт.

## 4. Программаның төп принциплары

Программаның төп принциплары булып тора:

- ярдәм күрсәтүне сорап кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының гариза язу тәртибендә мөрәҗәгать итүе;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасының һәркем өчен мөмкин булуы;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Программада каралган критерийларга туры килә торган барысы өчен дә үтемлелеген, тиешле программаларда катнашуга тигез дәрәҗәдә мөмкин булуны тәэмин итү; 2006 елның 26 июлендәге "Конкуренцияне яклау турында”гы 135-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп ярдәм күрсәтү;

- ярдәм күрсәтү процедураларының ачыклыгы.

## 5. Программаны тормышка ашыру срогы

Программаны тормышка ашыру срогы – 2019 – 2020 еллар.

## 6. Программа чаралары системасы

Программа чараларын тормышка ашыру 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы кысаларында, бюджет, бюджеттан тыш фондлардан финанслау, эшкуарларның үз акчалары, инвестицияләр җәлеп итү хисабына тормышка ашырыла. Программа чаралары билгеләнгән бурычлар нигезендә эшләнгән.

**2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы чаралары исемлеге**

| № | Чара төре | Нәтиҗә | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум) | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыгы | 2019 | 2020 | 2021 | |
| ***1. Кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше өчен шартларны камилләштерү*** | | | | | | | | |
| 1.1 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү һәм үстерү мәсьәләләрен җайга сала торган муниципаль норматив-хокукый база булдыру | Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә ярдәм | Финанслаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 1.2 | Ютазы муниципаль районы кече һәм урта эшкуарлык вәкилләренең ел саен үткәрелә торган конференциясендә катнашу | Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә ярдәм | Финанслаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 1.3 | Үсеш мәсьәләләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләүгә | Финанслаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | булмаган оешмалар, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек заимодействие с некоммерческими организациями, общественными объединениями предпринимателей, выражающими интересы субъектов малого и среднего предпринимательства с целью учета их мнения по вопросам развития малого и среднего предпринимательства | коммерциячел булмаган оешмаларны, эшкуарларның иҗтимагый берлекләрен җәлеп итү | | | | | | |
| 1.4 | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян фермер хуҗалыклары һәм башка авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр тарафыннан җитештерелә торган әзерләү продукциясе эшчәнлеген үстерү | Авыл хуҗалыгында кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешенә ярдәм итү | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акчалары | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| ***2.Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме*** | | | | | | | | |
| 2.1 | Аз санлы һәм ерактагы торак пунктларның көндәлек ихтыяҗ тауарлары белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарның бер өлешен компенсацияләү | Кече һәм урта эшмәкәрле субъектларына ярдәм (поддержка) | Бина (бүлмә) өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | Милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече һәм урта эшкуарлыкның һөнәрчелектә үсешенә ярдәм | Кече һәм урта эшмәкәрле субъектларына ярдәм (поддержка) | Бина (бүлмә) өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 2.3. | Яңа эшли башлаган кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм | Кече һәм урта эшмәкәрле субъектларына ярдәм (поддержка) | Бина (бүлмә) өчен аренда түләвеннән азат итү | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 2.4. | Яшьләр эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит чараларын алырга ярдәм итү | | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| ***3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультацион һәм мөлкәти ярдәм*** | | | | | | | | |
| 3.1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына оештыру ярдәмен гамәлгә ашыру һәм үстерү, шул исәптән: | | | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3.1.1 | "Ютазы муниципаль районы эшмәкәрләренең "Елның иң яхшы эшкуары" конкурсында катнашуларын оештыру | Эшмәкәрленең казанышларын пропагандалау (популярлаштыру) | Финанслаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3.1.2 | Җирлек мәгълүмат стендларында түбәндәгеләрне яктырту:<br>- юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати тәэмин итү | Финанслаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | теркәү тәртибе;<br>- эшмәкәрлек өлкәсендәге законнар;<br>- эшмәкәрлек өлкәсендә ярдәм итү;<br>анонс;<br>- файдалы мәгълүмат. | | | | | | | |
| 3.1.3 | Мәгълүмати стендларда эшмәкәрлекне кредитлау шартларын яктырту | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати тәэмин итү | Финанс лаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3.2 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультацион ярдәмне гамәлгә ашыру һәм үстерү | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм | Финан слаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм | Финанс лаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| ***4. Кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә социаль яклау хезмәтне саклау механизмнарын эшләү һәм кертү*** | | | | | | | | |
| 4.1 | Хезмәтне саклау буенча эшләрне оештыру сорауларында консультацион-методик ярдәм | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен яклау | Финанс лаудан башка | - | - | - | - | Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты |

## 7. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары программа чаралары исемлеге белән билгеләнә.

## 8. Программа белән идарә итүне оештыру (Программаны тормышка ашыру механизмы)

8.1 Программаны тормышка ашыру механизмы – ул билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итүче сроклар һәм җаваплы башкаручылар буенча координацияләнгән программа чаралары системасы.

Программаның заказчысы - Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты.

Программа чараларын үтәү 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында " 209-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә башкарыла.

8.2. П. 3. үтәлеше.3. Программа чаралары исемлеге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында " 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 9. Программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тоту

Программаны тормышка ашыру барышын Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты контрольдә тота.

## 10. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру җирлектәге икътисадый һәм социаль вәзгыятькә уңай йогынты ясаячак, инвестицион климатны яхшыртуга, җирлек инфраструктурасын үстерүгә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының көндәшлеккә сәләтлелеген арттыруга һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында, җирлектә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны арту белән, кече һәм урта бизнес секторында халыкның тотрыклы мәшгульлеген тәэмин итү өчен шартлар булдыру күздә тотыла.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программа чараларын финанслау дәрәҗәсенә һәм аларның үтәлешенә бәйле.

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын 10% ка арттыру;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләренең уртача санын, 2020 елга карата, 2018 ел белән чагыштырганда, 10 % ка арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлектә уртача хезмәт хакы күләмен уртача тармак дәрәҗәсендәгегә кадәр арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен 10 процентка  кадәр арттыру;
- җирлекнең инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту;
- кече һәм урта бизнес оешмаларының үз көчләре белән үзләре җитештергән, башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләмен, 2018 ел белән чагыштырганда, 2020 елга карата 10% ка арттыру.